**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«06 » май 2026 ел — № 7/2

**Тукай муниципаль районы «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 30 мартта 2/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге уставына таянып, Иске Абдул авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 30 марттагы 2/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советының 29.05.2020 ел № 5/1; 19.05.2022 ел № 17/2; 30.06.2023 ел № 28/1; 01.07.2024 ел № 42/2; 20.03.2025 ел № 51/2; 06.12.2025 ел № 3/2 карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«15.1. Муниципаль хезмәт вазифасын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль хезмәткәр эшкә алучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган, әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.».

1.2. 15.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«15.2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазифасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт бурычларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләрне Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм формада тапшырырга тиеш.».

1.3. 15.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«15.4. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге бүлек нигезендә тапшырыла торган белешмәләр, әгәр федераль законнар белән дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.».

1.4. 15.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«15.5. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге бүлек нигезендә бирелгән белешмәләрне муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының түләү сәләтен билгеләү өчен, дини яки башка иҗтимагый берләшмәләр, башка оешмалар, шулай ук физик затлар фондларына турыдан-туры яки читләтеп иганәләр җыю (взнос) өчен файдалану рөхсәт ителми.».

1.5. 15.6 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«15.6. Әлеге бүлек нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне ачуда яки әлеге белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда куллануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка ия.».

1.6. 15.7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«15.7. Муниципаль хезмәткәр тарафынан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр һәм «Дәүләт вазифаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләрне, әгәр мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булса, тапшырмау яисә белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу була, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш.»;

1.7. 15.12 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

1.8. 17.2.1 пунктының 10 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;».

2. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм махсус стендларда, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында tukay.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
Совет Рәисе
Р.Х.Сафина